«Татмедиа» ААҖ филиалы
«Ялкын» журналы редакциясе»

татмедиа

Филиал ОАО «Татмедиа»
«Редакция журнала «Ялкын»

яшүсмерләрнең айлык
әдәби-нәфис журналы

Ялкын®

ежемесячный
литературный
иллюстрированный
журнал для подростков

420066, г. Казань, ул. Декабристов, 2, тел. (843) 562-11-22, 562-11-57, факс 562 12 31
www.yalkyn.ru e-mail: yalkin@bk.ru

21-11/14 21.11.2014

Актаныш районы
Мәгариф идарәсе җитәкчесе
**Л.Ф. НУРЛЫЕВА**га

**Хөрмәтле Ләйсән Фоатовна!**

Татарстанда яшүсмерләр өчен нәшер ителүче бердәнбер журнал – **«Ялкын»** Сезнең район укучылары һәм укытучылары белән тыгыз элемтәдә тора. Район мәктәпләренә очрашуларга, мастер-класслар уздырырга еш киләбез. Актаныш укучылары журналга актив яза, 2 укучы – Илгиз Шәкүров һәм Лилия Гәдерәхимова журналның балалар редколлегиясе составына керә. Даими язучылар арасында Ләйлә Исламова, Инзилә Мәҗитова, Айдар Шәйхин бар.

Узган яртыеллыкка язылу нәтиҗәләре буенча **Актаныш районы өченче урында булды.** Без бу хакта хәтта журналыбызның тышлыгында да язып чыктык. Бик зур рәхмәт Сезгә!

Инде менә яңа яртыеллыкка **(гыйнвар – июнь 2015)** язылу чоры кызу темплар белән бара. Әлегә, кызганычка каршы, күрсәткечләр әллә ни куанырлык түгел. «Татарстан почтасы» тапшырган соңгы мәгълүматлар буенча, Актаныш районыннан нибары 26 язылучы гына теркәлгән.

**Ләйсән Фоатовна!** Районыгыз укытучылары һәм укучыларына **«Ялкын» журналына язылырга** Сезнең тарафтан да **өндәмә (хат, мөрәҗәгать)** булса, бу язылу нәтиҗәләрен арттырыр иде. 2015 елның беренче яртыеллыгына «Ялкын» журналына язылу бәясе – **270 сум. Язылу 30 декабрьгә кадәр дәвам итә.**

«Ялкын»га язылып, бүләк оту мөмкинлеге дә бар. Ноябрь аеннан **«Ялкын»га языл һәм Санкт-Петербургка сәяхәт от»** дигән бәйге игълан иттек. Бәйгедә катнашу өчен класстагы һәр укучыга “Ялкын”га язылырга, класс белән үзенчәлекле формада таныштырырга кирәк булачак. Үзләре белән **иң кызыклы итеп таныштырган 4 класс җиңүче** дип игълан ителәчәк. Бәйгенең төп бүләге

Санкт-Петербургга сәяхәт булыр дип планлаштырыла. Башка җиңүчеләр ноутбук, пинг-понг өстәле, мультимедиа-проектор белән бүләкләнәчәк.

Мәктәпләрне сыйфатлы, нәкъ менә аларга юнәлтелгән басма белән тәэмин итүдә Сезнең теләктәшлеккә һәм ярдәмегезгә ышанып калабыз.

Яңа буын зыялы татар яшьләрен бергәләп тәрбиялик!

Ихтирам белән,
«Ялкын» журналының
баш редакторы МИҢНУЛЛИНА Й.Ф.

Элемтә өчен: 8 (843) 562-11-22, 8-9053-172191 (Ләйсән Фәйзуллина)
E-mail: yalkin@bk.ru